КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 26 февраль г.Казань № 167

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Музей фонды торышын төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 937 нче карары белән расланган Россия Федерациясе Музей фонды торышын төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымтага үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Музей фонды торышын төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 30 сентябрь, 937 нче карары белән расланган Россия Федерациясе Музей фонды торышын төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымтага, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлгән).

2. Бу карар 2022 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Россия Федерациясе Музей фонды торышын төбәк дәүләт контролендә (күзәтчелегендә) тоту турындагы нигезләмәгә 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 26 февраль, 167 нче карары редакциясендә)

Россия Федерациясе Музей фонды торышын төбәк дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) төп һәм индикатив күрсәткечләре

Төп күрсәткечләр

| Т/с | Төп күрсәткеч исеме | Еллар һәм төп күрсәткечләрнең максатчан (фараз) мәгънәләре | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 ел (база мәгънәсе) | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел |
| 1. | Татарстан Республикасында музейларның гомуми санынннан музей фонды әйберләрен саклау (иминлек) шартлары тәэмин ителә торган музейларның өлеше, процент | ≥ 6,2 | ≥ 6,4 | ≥ 6,6 | ≥ 6,8 |

Индикатив күрсәткечләр

1) хисап чорында план буенча үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

2) хисап чорында планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

3) хисап чорында контрольдә тотылучы объектның мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторларында расланган параметрларга туры килүен яки контрольдә тотылучы объектның мондый параметрлардан читкә китүен ачыклау нигезендә планнан тыш үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

4) хисап чорында хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чараларының гомуми саны;

5) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларының һәр төре буенча хезмәттәшлек итеп үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

6) хисап чорында үзара дистанцион хезмәттәшлек итү чараларыннан файдаланып үткәрелгән контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

7) хисап чорында үткәрелгән мәҗбүри профилактик визитлар саны;

8) хисап чорында мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау турында игълан ителгән кисәтүләр саны;

9) хисап чорында нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрнең бозылуы ачыкланган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

10) хисап чорында йомгаклары буенча административ хокук бозулар турында эшләр кузгатылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны;

11) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чаралары нәтиҗәләре буенча салынган административ штрафлар суммасы;

12) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән гаризалар саны;

13) хисап чорында контроль (күзәтчелек) чараларын үткәрүне килештерү турында прокуратура органнарына җибәрелгән һәм прокуратура органнары тарафыннан килештерелмәгән гаризалар саны;

14) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы объектларның гомуми саны;

15) хисап чоры ахырына исәпкә алынган, риск категорияләренә кертелгән контрольдә тотылучы объектларның риск категорияләрендәге һәрберсе буенча саны;

16) хисап чоры ахырына исәпкә алынган контрольдә тотылучы затлар саны;

17) хисап чорында исәпкә алынган һәм аларга карата контроль (күзәтчелек) чаралары үткәрелгән контрольдә тотылучы затлар саны;

18) хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән шикаятьләрнең гомуми саны;

19) хисап чорында контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) орган тарафыннан карап тикшерү срогы бозылган шикаятьләр саны;

20) хисап чорында контрольдә тотылучы затлар тарафыннан судка кадәрге тәртиптә бирелгән, карап тикшерү йомгаклары буенча контрольдә тотучы органның карарын тулысынча йә өлешчә гамәлдән чыгару турында яисә контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органнарның вазыйфаи затлары гамәлләрен (гамәл кылмавын) гамәлдән чыккан дип тану турында карар кабул ителгән шикаятьләр саны;

21) хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органның карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында җибәрелгән дәгъва гаризалары саны;

22) хисап чорында контрольдә тотылучы зат тарафыннан контрольдә тотучы (күзәтчелек итүче) органның карарлары белән, вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәү турында җибәрелгән, белдерелгән таләпләрне канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән дәгъва гаризалары саны;

хисап чорында дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата таләпләрне тупас бозып үткәрелгән һәм нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылган һәм (яки) гамәлдән чыгарылган контроль (күзәтчелек) чаралары саны.